وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№16 (113). 2 декабрь 2011 / 7-мөхәррәм-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Тукайны Төркия дә онытмый ▷2◁



Чәршәмбе, кич: эшләр планлаштырмаска ▷3◁




Фәхретдин ишан ▷3◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**КАТОЛИКОС БЕЛӘН ОЧРАШУ**

29 ноябрь көнне БДБ илләренең Дин-ара шурасы кысаларында Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз Әрмән Апостоль чиркәвенең башлыгы, югары патриарх һәм барлык әрмәннәрнең Католикосы Гарегин II белән очрашты. Очрашу II гасырның икенче яртысында төзелгән әрмән патриархы резиденциясендә - Эчмиадзинда үтте. Дин әһелләре бүгенге җәмгыятьтә әдәп-әхлакны саклау һәм әлеге проблемаларны чишүдә традицион конфессияләрнең роле турында фикер алышты.

**СӘЛӘТЛЕ МӨСЛИМӘЛӘР ӨЧЕН I РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ "ЭНҖЕ" БӘЙГЕСЕ**

ТР мөселманнары Дини нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге мөслимәләр өчен "Энҗе" дип исемләнгән кул эшләре бәйгесе оештыра. Бәйге күргәзмә-сату формасында үтәчәк.

"Кул эшләнмәләреннән ясалган иң уңышлы, оригиналь композицияне кыйммәтле бүләк көтә. Моннан тыш, күптөрле номинацияләрдә истәлекле бүләкләр биреләчәк. Сатылмый торган әйберләр арасында да аерым бәйге булыр дип уйлыйбыз", - ди оештыручылар.

Хенд-мейд күргәзмәсе көнендә күптөрле мастер-класслар оештыру да каралган. Скрапбукинг, декупаж, квиллинг, психология, макияж һәм башка темаларга мастер-классларда катнашу түләүсез булачак.

Шулай ук биредә мөслимәләр өчен киемнәр коллекциясен тәкъдим итү дә каралган.

Әлеге чарада кул эшләнмәләрен тәкъдим итү, үз композицияң белән катнашу өчен гаризалар 6 декабрьгә хәтле dummol@inbox.ru адресына кабул ителә.

Сораулар өчен тел: +7 (843) 264-61-58.

**МӨХТӘСИБЛӘР ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШТЫ**

28 ноябрьдә Саба районында Саба, Балтач, Арча, Яңа Чишмә, Нурлат, Апас, Кайбыч, Чистай районнары имам-мөхтәсибләренең җыелышы үтте. Әлеге чарада мөхтәсибләр үз тәҗрибәләре белән уртаклашты. Җыелышта ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең гомуми бүлек җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев катнашты.

**ФӘНИС ЯРУЛЛИН БЕЛӘН ОЧРАШУ**

29 ноябрь көнне "Зәкят" хәйрия фонды вәкилләре Халыкара инвалидлар көне уңаеннан Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай һәм М.Җәлил исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, "Халыклар дуслыгы" ордены кавалеры Фәнис Яруллин белән очрашуда булды.

# Әдәп-әхлак гасыры

**Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре. 28 ноябрьдә Ереванда үткән Бәйсез Дәүләтләр Берлеге (СНГ) илләре Дин-ара советының президиум утырышында катнашты.**

**Миңа БДБ илләренең мөселман, христиан, яһүд һәм будда динен тотучы җәмгыятьләренең җитәкчеләре һәм вәкилләре белән очрашу һәм алар белән безне борчыган көн үзәгендәге сорау һәм проблемалар буенча фикер алышу мөмкинлеге бирелде.**

**Сезнең игътибарыгызга мин утырыш нәтиҗәләре буенча кабул ителгән документны тәкъдим итәсем килә.**

**Төп проблема һәм төрле начар эшләрнең чыганагы булып, җәмгыятьтәге әхлаклылыкның түбән дәрәҗәдә булуы тора.**

**Әхлаксызлык һәм рухи кыйммәтләрне санга сукмау кешеләрнең кыргыйлануына китергән кебек, җәмгыятьтәге аерым төркемнәренең дә кыргыйлануына китерә.**

**Моның нәтиҗәсе буларак, этник һәм "дини" экстремизм барлыкка килә.**

**Якын Көнчыгышта һәм Төньяк Африкада баручы вакыйгаларга карап, без халыкларның табигый ирекkә омтылышы тәртипсезлеккә, дин ирегенең, кеше хокукларының бозылуына алып килүен, аның уңышсыз булуында шикләнмибез.**

**Шул ук вакытта без, рухи җитәкчеләр, XXI гасырның афәте - террорчылыкның кешеләрдә әхлак башлангычы зәгыйфьләнүенең нәтиҗәсе икәнлеген раслыйбыз. Бер гаепсез кешеләрне үтерүчеләр, терактны оештыручылар кебек үк, коточкыч явызлыкларын эшләгәнче үк инде үз-үзләрен рухи яктан үтергән.**

**Шәхси әхлак югалу җәмгыятьнең әхлаксызлануына китерә. Без моны бик күп мисалларда күрә алабыз.**

**Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр сату-алу яссылыгына күчә.**

**Гаилә турында традицион күзаллаулар бозыла, нәтиҗә буларак, алар тәртипсезлек, бозыклык, эгоизм һәм ваемсызлык учагына әйләнә. Әти-әниләре исән-сау була торып, балалар ятим кала, алар гаиләдә һәм мәктәптә әдәп-әхлак тәрбиясе алмый, физик һәм психик үсештән артта кала.**

**Массакүләм мәгълүмат чаралары да кешеләр алдында булган җаваплылыклары турында оныта һәм бу начар нәтиҗәләргә китерә. Сәясәт һәм әхлаклылыкның бәйләнеше турында искәртеп үтәсебез килә. Күп кенә кеше: "Сәясәт һәм әхлаклылык - бер-берсенә каршы", - дип исәпли. Чыннан да, бүгенге көндә әдәп-әхлак кагыйдәләрен саклаучы сәясәтчеләр бик аз. Кызганыч, сәясәтчеләрнең әхлаксызлыгы җәмгыятьтә коррупция үсешенә юл куйды һәм ваемсызлык тудырды.**

**Без: "Әхлаклылык аерым кешенең иминлеген һәм бәхетен генә түгел, ә гомумән, халыкның уңышлылыгын билгели", - дип исәплибез. XX гасыр фәнни-техник революция гасыры булган кебек, XXI гасыр әдәп-әхлак гасыры булыр, дигән өметтә калабыз.**

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**ТР мөселманнары**
**Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# Гашура көне



***Мөхәррәм аенда бер көн бар. Ул көнгә Гашура дип әйтәләр. Гарәп теленнән "гашура" дигән сүз "унынчы" дип тәрҗемә ителә. Пәйгамбәребез (сгв) Мәккә-Мөкәррәмә шәһәреннән Мәдинә-әл-Мөнәвварә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән Бәни Исраил кавеменнән булган кабиләләрнең бу көндә ураза тотканнарын күреп: "Нинди ураза бу? Кайдан килгән гамәл бу?" - дип сораган. Һәм теге Бәни Исраил кавеменнән булучылар: "Бу көндә Аллаһның рәхмәте белән пәйгамбәребез Муса (гс) үзенең кавемен - Бәни Исраил токымын фиргавен залимнән коткарды. Бу көнне олылап без ураза тотабыз", - дигән. Бу сүзләрне ишеткән пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Бу уразага без (мөселманнар) Муса пәйгамбәребезнең шушы гамәленә караганда да (Аллаһның бәндәләре) күпкә лаеклырактыр", - дигән. Һәм рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) хәзрәтләре шушы көнне уразада булган.***

Ул үзенең өммәтен, мөэмин-мөселманнарны да бу көндә ураза тотарга өндәгән. Тарихка күз салсак, Мөхәррәм аендагы Гашура көне - ул истәлекле бер көндер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) Аллаһ Раббыбыздан вәхи иңгәнчегә кадәр, хәтта җаһилияттә яшәгән, Аллаһка ширек каткан гарәпләр - Кураеш кабиләсе дә ураза тота торган булган. Яһүдиләр дә шулай ук уразада булган. Кайбер риваятьләрдә әйтелгәнчә, хәтта нәсраниләр дә ураза тоткан дигән хәбәрләргә юлыгабыз. Бу көндә пәйгамбәребез Нух (гс) туфан суыннан котылган. Ибраһим (гс) шулай ук Раббысының рәхмәтенә ирешкән. Бу - бөек бер көндер. Пәйгамбәребез (сгв) шушы көнгә карата тагын: "Әгәр дә киләсе елда мин Мөхәррәм аена ирешә алсам, һичшиксез, Мөхәррәм аеның унынчы һәм унберенче көннәрендә уразада булыр идем", - дип әйткән булган. Ләкин пәйгамбәребез (сгв) шушы Мөхәррәм аен күрә алмыйча, Аллаһ Раббыбызга мөшәррәф җанын тәслим кыла...

Әй, кардәшләрем! Ураза - әйтүемчә, бөек гыйбадәтләрдәндер. Ураза - ул безне Раббыбыз белән бәйли торган яшерен, серле бер силсилә булып тора. Адәм баласы уразадан кала кылган һәр гамәлен (намаз уку, ашарга пешерү, эшкә бару, балалар тәрбияләү һ.б.) үзе өчен эшли. Аллаһның кодси хәдисләрен пәйгамбәребез (сгв) безгә китерә. "Ураза - ул минеке. Һәм аның әҗер-савабын Мин сезгә Үзем бирермен", дип вәгъдә иткән Ходай Тәгалә.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*



***- Мин 1968 елда Баулы районында туганмын. 1985 елда урта мәктәпне тәмамладым. Шул ук елны Казан авыл хуҗалыгы институтына кердем. Аны укып бетергәч, һөнәрем буенча сигез ел эшләдем. Эш барышында үземә кечкенә генә нәтиҗә ясадым: авыл хуҗалыгы тармагының киләчәге өметле түгел икән. Дин булмаса, гомумән, авылның да киләчәге булмас. Безнең авыл-шәһәрләрнең киләчәген, аның эшчәнлеген, тулаем алганда, яшәешебезне фәкать дин генә саклап калачак, дип уйлап, үзем дә дингә килдем, - дип башлады үз сүзен хәзерге вакытта Түбән Кама мәдрәсәсе директоры вазифаларын башкаручы Рафикъ хәзрәт.***

### *Рафикъ хәзрәт ИСЛАМГАЛИЕВ:*

# "БЕЗГӘ БУЙСЫНУ ҖИТМИ"

***- Сез дингә кайчан кереп киттегез? Дин белән кызыксынуыгыз ни рәвешле башланды? Кыскача гына үзегезнең дини эшчәнлек белән таныштырып китә алмассызмы икән?***

- 1998 елда Түбән Кама мәдрәсәсенә укырга кереп, аны 2000 елда тәмамладым. Аннан соң 2002 елга кадәр Баулы шәһәрендә һәм Баулы районында имам-мөхтәсиб булып эшләдем. Шул дәвердә төрле чаралар үткәрү насыйп булды. Төзелеш эшләре алып бардык: Баулы Җәмигъ мәчете авария хәлендә иде, мәчетне торгызуда гаять зур активлык күрсәтергә туры килде. Мәчетнең фундаменты тиешле таләпләргә җавап бирмәгәнлектән, мәчет берничә урыннан ярылып, җимерелергә тора иде. Гыйбадәтханәне төзекләндереп бетергәннән соң, мәчеттә укытулар алып барылды, төрле шәхесләр белән очрашулар оештырылды. Әйтергә дә онытып торам икән, 2001 елда Сириягә барып, гарәп теле буенча курсларда укыган идем. Шунда укыганда хәнәфи мәзһәбе, матуриди гакыйдәсе белән якыннанрак таныштым һәм, һичшиксез, монда килеп укырга кирәк икән, дип уйлап куйдым. 2002 елда гаиләм белән Дамаскка күчтем. Барыбыз да гыйлем алырга тотындык. Бу Согудия илләре түгел, Сирия - икътисади яктан алга китмәгән, анда эшләргә дә, яшәргә дә бик авыр. Шуңа күрә дә мин үз ватанымнан - Россиядән киткәндә барлык байлыгымны, хәтта өемне дә сатып киткән идем.

*(Ахыры 4 нче биттә)*

# Тукайны Төркия дә онытмый



***Татар халкының күренекле улы, шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулу җәһәтеннән ТӨРКСОЙ халыкара төрки милләтләр мәдәнияте оешмасы агымдагы елны Тукай елы дип игълан иткән иде. Бу уңайдан Төркиядә шактый зур эшләр башкарылды. Әнкарадагы Г.Тукай исемен йөртүче урам башына шагыйрьнең бюсты куелды. Истанбулда тарихи бер районның иң матур җиренә урнашкан паркка һәм Тарсус шәһәрендәге яңа бульварга Тукаебез исеме бирелде. Аеруча, төрле концертлар, тамашалар оештырылды.***

Инде килеп, шагыйребезне юбилее нисбәтеннән олылап, халыкара Ислам тарихын, сәнгатен һәм мәдәниятен фәнни өйрәнү үзәге (ИРСИКА) фәнни-гамәли конференция оештырды. Ул Истанбулда соңгы госманлы солтаннары яшәгән затлы "Йолдыз" сараенда, 2007 елның февраль аенда Татарстан Президентын кунак иткән, шул ук вакытта Татарстан мәдәният министрлыгы белән "Хезмәттәшлек меморандумы" имзаланган залда узды.

Җыенда Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, ТӨРКСОЙ оешмасы җитәкчеләре, Россия Федерациясенең Төркиядәге дипломатлары, Истанбулның Бәйоглу һәм Фатих районнары җитәкчеләре, фән эшлекләре, аз санлы булса да татар диаспорасы вәкилләре, студентлар, журналистлар катнашты.

Җылы атмосферада үткән чарада ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова кунакларны сәламләп, татар илбашы Рөстәм Миңнехановның конференция уңаеннан махсус җибәргән хатын ирештерде. Татарстан президентының ИРСИКА оешмасы җитәкчелегенә Тукайны игътибарсыз калдырмаулары өчен рәхмәт белдергән хатында: "Тукай иҗатына бәя биреп бетерерлек түгел. Ул тарихка нечкә лирик, үткен сатирик һәм татар-төрки халыкларының күп гасырлык әдәби мирасын гомумиләштерергә ирешкән гаҗәеп каләм остасы буларак кереп калды. Кыска гомере эчендә ул татар мәдәниятен генә түгел, тулаем дөнья әдәбиятын баеткан күп санлы әсәрләр язды. Г.Тукай шигырьләренең музыкаль яңгырашы аша милли әдәбиятның яңа юнәлешләре ачылды. Аның иҗатында халык һәм шагыйрь төшенчәләре аерылгысыз. Нәкъ менә шуңа да Тукай поэзиясе халык уй-теләкләренә һәрчак аваздаш булды", - диелә. Римма Ратникова шулай ук ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм депутатларның кайнар сәламнәрен дә җиткерде. Чыгышын Г.Тукайның "Шагыйрь" шигыреннән бер өзек белән тәмамлады.

Җыенда махсус доклад белән чыккан ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин Г.Тукай елы уңаеннан Татарстанда гына түгел, Россиянең бик күп төбәкләрендә төрле чаралар оештырылуын әйтеп узды. Агымдагы елны төрки дөньяда Г.Тукай елы игълан итүләре өчен ТӨРКСОЙ оешмасына рәхмәт хисләрен белдерде.

Чара кызыклы докладларга бай булды. Бигрәк тә төрек галимнәренең Тукай белән кызыксынуы артканлыгы сизелеп тора. Эрзурум шәһәреннән килгән Ататөрек исемендәге университет профессоры Гөлхан Атнур Г.Тукайның балалар өчен язган әсәрләрен анализлады. Әнкара университетының япон теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты Мәртхан Дүндар Тукай шигырьләрендә һәм аның публицистикасында Япония сәясәтенә һәм японнарга булган мөнәсәбәте турында кызыклы доклад белән чыкты. Истанбулдагы Мәрмәр университеты галиме Исмәгыйль Түркоглу Г.Тукайның тәнкыйтьче булуы, бигрәк тә Муса Бигиев белән Йосыф Акчурага аткан тәнкыйть уклары турында мәгълүмат бирде. Шагыйрь тәнкыйтенә дучар булуга карамастан, Бигиев белән Акчураның Габдулла Тукайны милләт сакчысы итеп күргәнлекләрен белдерде.

ТР Фәннәр академиясеннән килгән фән эшлекләренең чыгышларын халык йотылып тыңлады. Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры Резеда Ганиеваның ялкынлы чыгышы Тукайның Төркия белән булган мөнәсәбәтләрен, Төркиягә карашын чагылдырды. Госманлы империясенең соңгы көннәрендәге кискен сәяси мөнәсәбәтләрен күзәтеп барган Тукайның: "Төркия - күктә очкан бөркет иде", - дигәнен искәртте, кырыклап әсәренең госманлы-төрек теле тәэсирендә язылганын хәбәр итте. Шул ук уку йорты галиме Таһир Гыйләҗев Җәмал Вәлидинең Г.Тукай буенча язган әсәрләре белән таныштырды. Ул Вәлидинең шагыйрьгә беренче монографик әсәр язган һәм Тукай фәненең тәүге нигез ташын салган зат булганлыгы турында сөйләде. Габдулла Тукайның бүгенгәчә фәнни биобиблиографиясе булмаганлыгын белдереп, бу кимчелекне төзәтү зарурлыгын бәян итте.

Күренекле галим Зөфәр Рәмиев Г.Тукай әсәрләренең алты томлыкларын нәшер итү хакында киң мәгълүмат бирде. Ул: "Быел Тукай юбилеена ике томы чыккан академик басманың калган бер томын якындагы ике-өч елда әзерләп, бастырып чыгару буенча эш алып барыла", - диде. Галим совет чорында төзелгән томнардагы идеология, режим аркасында килеп чыккан кимчелекләрне дә телгә алды.

Диләрия Абдуллина исә Тукай иҗатындагы ислам дине мотивлары турында сөйләде. Аның чыгышы совет чорында Тукайны атеист итеп күрсәтергә тырышкан кайбер хезмәтләргә җавап булып яңгырады кебек. Ул, Тукай иҗатына дога жанры, Аллаһка мөрәҗәгать итү, аны зурлау хас икәнлеген ассызыклады. Нәниләр өчен язылган әсәрләрендә дә Коръән мотивларын еш очратырга мөмкин булуын, сүрәләргә нәзирәләр язганын белдерде. Шигырьләрендә аятьләргә нигезләнгән юлларның күплеген, иҗатының Коръәни-Кәрим белән уртаклыгы, тыгыз үрелгән булуын искәртте.

Халыкара ИРСИКА оешмасының Истанбулда үткән Г.Тукай конференциясе шагыйрь сүзләренә халык иҗат иткән "И туган тел" җыры белән тәмамланды.

*Рушания АЛТАЙ,*
**Истанбул**
**Автор фотосы**

**Айрат СИБАГАТУЛЛИН, Татарстан Республикасы мәдәният министры:**

- Тукай шигъриятендә татар халкының җаны яши. Ә җан, белүебезчә, үлемсез. Һәм ул җир үлчәмнәре белән үлчәнми. Димәк, Тукайның иҗаты - үлемсез. Аның әсәрләре милли мәдәниятнең үткәне, хәзергесе һәм киләчәге белән тыгыз бәйләнгән... Бу конференция Тукайга булган кызыксынучанлыкның артуын күрсәтүче ышандырырлык дәлил булуын ассызыклады.

**Халит ӘРӘН, чараның хуҗасы, ИРСИКА гомуммөдире:**

- Татар мәдәниятендә аерым урын тоткан мәгънәви вә милли символ Г.Тукайның тууына 125 ел тулу елында бу конференцияне оештыруыбыз өчен без бик бәхетле. Тукай XX гасыр башында татар зыялылары һәм сәнгать дөньясында шигырьләре вә фикерләре белән татар әдәбиятының әһәмиятле вәкиле буларак урын алып тора. Аның бик кыска тормышына һичбер вакыт онытылмас, еллар узган саен әһәмияте тагын да яхшырак аңлашыла башлаган һәм бүгенге чорда яңа фәлсәфи мәгънә вә әһәмият казанган кыйммәтләр, мөһим әсәрләр сыйган. Иҗаты, һичшиксез, исемен ерак гасырларга илтәчәк. Г.Тукай татар халкының гына түгел, бөтен төрки дөньяның күтәрелгән мәдәни кыйммәтләренең символ исеме булды. Мәрхүм Тукай хезмәтләрендә татар халкының рухи байлыкларын олылаган, шул ук вакытта халкының иҗтимагый мәсьәләләрен дә яктырткан. Милләтенең яктылыкка ирешүе һәм уңайлы шартларда яшәвен теләп янган. Габдулла Тукайның әсәрләре һәм татар халкы, һәм төрек дөньясы өчен зур әдәби мирас. XX гасырдагы социаль буталчыклар чорында яшәгән Тукайның идеологик фанатизмга бирелмәве аның зур шәхес һәм фикер иясе булуын исбатлый. Мәдәният тарихының мөһим бер шәхесе буларак, ул - милләтләр һәм мәдәниятләр арасында зур әһәмияткә ия.

**Зөфәр РӘМИЕВ, ТР Фәннәр академиясендәге Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы:**

- Тукайны нәшер итү - шагыйрь вафат булган көннәрдән башлана. Г.Тукай 1913 елда Клячкин шифаханәсенә керер алдыннан үзенең җыентыгын эшли, ул аңа кайбер әсәрләрне кертми калдыра (китап 400 битле булыр, дип уйланылган була). Җыентыкны Тукай вафат булгач, Җамал Вәлидинең кереш сүзе белән бастыралар. Шуннан соң Тукайның өчтомлыгы 1929-1931 елларда, икетомлыгы 1943 һәм 1948 елларда, 1955-1956 елларда дүрттомлыгы, 1975-1976 елларда янә дүрттомлыгы һәм 1985-1986 елларда биштомлыгы басылды. Безнең институт быел Тукайның яңа басмасын әзерләде - ул алтытомлы академик басма. Акамедик басма дигән сүз - ул Тукайның бөтен әсәрләре дә кертелеп, комментарийлар белән чыгару. Бу классик мирасны бастыруның иң югары басма тибы.

# Пакыстан АКШтан торган саен ераклаша бара

***Күптән түгел берничә НАТО (Организация Североатлантического договора) вертолёты Әфганстан ягыннан Пакыстанның һава киңлекләрен бозып, дәүләтнең төньяк-көнбатышында урнашкан Моманд өлкәсендәге блокпостка ут ача. Бу һөҗүмдә 28 кеше һәлак була һәм 14 кеше яралана. Бу хакта Пакыстан массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәр итте.***

АКШтагы Пакыстан илчесе вазифаларын башкаручы Иффат Гардези Америка Дәүләт департаментына протест белдерде, дип яза itar-tass.com сайты.

Әфганстандагы НАТО көчләре җитәкчелеге һәлак булган Пакыстан хәрбиләре туганнарының һәм якыннарының кайгыларын уртаклашты. Шул ук вакытта НАТО Пакыстан хәрбиләренең һәлак булуы нәкъ менә аларның вертолётлары һөҗүме нәтиҗәсендә булуын танымый.

Әфганстан җирлегендәге альянс гаскәрләре җитәкчесе генерал Джон Аллен Пакыстандагы хәрбиләрнең вафат булу очрагын тикшерү башлануы турында белдерде. "Бу вакыйганы тикшерүне мин үз күзәтүем астында тотачакмын. Барлык фактларны да ачыклау өчен, барысын да җентекләп тикшерергә кирәк", - диелә аның белдерүендә.

Пакыстанны бу аңлатмалар канәгатьләндермәде һәм алар җавап кайтарырга ашыкты. Хәрби көчләр илнең төньяк-көнбатыш чиген, аерым алганда Джамруттагы КППны НАТО хәрби транспорты өчен япты. Бу Әфганстандагы НАТО гаскәрләре тәэмин ителешен туктатуга китерде.

Хәзерге вакытта КПП янында кырыклап йөк автомобиле һәм бензовоз тупланды.

Әфганстанда урнашкан НАТО гаскәрләре тәэмин ителешенең 70 проценты Пакыстан аша башкарыла.

Пакыстан хәрбиләренә НАТО вертолётларының һөҗүм итүләре беренче тапкыр гына түгел. 2010 елның 30 сентябрендә Әфганстан белән чик Оразкай кабиләсе җирлегендә НАТО вертолётлары Пакыстан хәрбиләренә ут ачкан иде инде. Ул вакытта ике кеше һәлак булган, дүртесе яраланган. Шул очрактан соң Пакыстан җитәкчелеге Әфганстандагы НАТО гаскәрләре өчен Пакыстан территориясе аша үтә торган йөкләрне тыярга карар кылган иде. Бу тыю ун көннән, АКШ гафу үтенгәннән соң гына алынды.

Пакыстан элитасының күпчелеге Америкага мөкиббән булса да, халык арасында Америкага каршы карашлылар шактый күп һәм НАТОның мондый һөҗүмнәре аларның санын арттыра гына.

Шимбә көнне булып үткән Пакыстанның Министрлар Кабинеты һәм хәрби җитәкчелек вәкилләренең киңәшмәсендә АКШ белән мөнәсәбәтләрне яңадан тикшереп чыгарга кирәк, дигән нәтиҗәгә килде. Бу хәзерге вакытта НАТО һәм АКШ белән дипломатик, сәяси, хәрби өлкәләрдә булган килешүләргә кагылачак. Америкадан унбиш көн эчендә Шәмси хәрби базасын калдыруны таләп иттеләр, дип хәбәр итә "DawnNews" телеканалы.

**ISLAM.RU**



# Чәршәмбе, кич: эшләр планлаштырмаска

***Яшьләр һәрвакыт җәмгыятьтә зур роль уйнаучы төркем булып тора. Үз фикерләрен тормышка ашырырга теләгән лидерлар да яшьләр белән эшләүне өстенрәк күрә, чөнки алар һәрвакыт яңалыкка, тормышны яхшыга үзгәртергә ашкынып тора. Тормыш матураер, ямьләнер дигән якты уйлар белән яшиләр. Дөньяның алга китешенә тамчы гына булса да үз өлешен кертү теләге белән янып, җәмгыятькә, кешеләргә файдалы булу турында хыялланалар. Казанның татар мөселман яшьләре буш вакытларын ничек уздыра соң? Нинди уй-теләкләр белән янып йөри алар? Бу язмамда мин шушы сорауларга җавап табарга телим.***

Казанда татар яшьләренә үсү, вакытны файдалы һәм кызыклы үткәрү өчен мөмкинлекләр бик күп. Театр, музей, концерт, кино, күргәзмәләр турында әйтеп тә торасы юк. Шулай ук Казанда "Шәрык", "Фикер", "Алтын урта" клублары эшли. Аларның һәрберсенең үз максаты, үз юнәлеше, үз аудиториясе бар. Ә хәзер соңгысы турында тулырак.

"Алтын урта" моннан бер ел элек оеша. Баштарак ул мастер-класслар үткәрү белән шөгыльләнә, ә февраль аеннан Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте составына кергәч, ул инде эшчәнлеген киңәйтә: атна саен очрашулар үтә, кызлар клубы эшли башлый, активистлардан торган төркем өстәмә чаралар оештыра. "Алтын урта" клубының максаты - татар мөселман яшьләрен бергә туплау, аларны төрле радикаль агымнарга иярүдән саклап калу, тормыш офыкларын киңәйтү.

"Алтын урта" һәр чәршәмбе һәм җомга көнне очрашулар оештыра. Чәршәмбе көнне очрашуга һәркем килә ала, ә җомга көнне егетләргә ишекләр ябык, бу көнне кызлар өчен оештырылган махсус кичәләр була. Очрашуларга тормышның төрле өлкәсенә караган һөнәр ияләре һәм дин белгечләре килә. Һәр очрашу кызыклы һәм, иң мөһиме, файдалы үтә. Катнашучылар үзләрен борчыган сорауларга җавап таба ала. Бергә-бергә уртак проектлар төзелә.

Клубның аудиториясен күбесенчә дини яшьләр тәшкил итә. Төрле уку йортларыннан җыелган бу яшьләрне дөньяны яхшыга үзгәртү, аны аз булса да начарлыклардан арындыру теләге берләштерә. Авыр хәлдәге кешеләргә булышуда төрле акцияләр үткәрелә. Төрле чараларда актив катнашып, музейларга, күренекле шәхесләргә кунакка барып, хәйрия эшләре оештырып, намаз укыган егетләрнең һәм яулык кигән кызларның бер дә ябылып кына ятмаганлыгын, ә актив тормыш алып барганлыгын исбатлый алар.

Бәйрәмнәр дә шәригать кануннарына хилафлык китермичә, бик күңелле һәм файдалы уза. Үзләренең тормышка шундый карашлары белән бу яшьләр бик күпләргә үрнәк булып тора һәм җәмгыятьтә туган бик күп стереотипларга нокта куя. Үз араларында гына йөргән шаяртулары да бар, шуларның берсе яңа килүчеләргә әйтелә: "моннан кирегә юл юк". Чыннан да кичәләрең берәрсенә килгән кеше, актив катнашучыга әверелә.

"Алтын урта" - ул, шулай ук, дусларның очрашу урыны да, Казанның төрле почмакларында, төрле өлкәләрдә яшәгән, ә ял көннәрендә башка эшләр белән мәшгуль кешеләр нәкъ менә "Алтын урта"да очраша, аралаша, соңгы яңалыклар белән бүлешә, әңгәмә ахырында ярый әле "Алтын урта" бар, ничек кенә күрешергә җай табар идек, дип өстәп куела.

Әлбәттә, эш барышында җитешсезлекләр дә булгалыйдыр, әмма хата булмасын дип, тик кенә утыру - ул үзе хата булыр иде. Иң мөһиме: мондагы яшьләр һәрвакыт үз өсләрендә эшләргә, яхшырак булырга омтыла. Кыскача әйткәндә, "Алтын урта" да тормыш гөрли. Ә без исә клуб турында күбрәк белергә теләүчеләрне мөфтияттә көтеп калабыз. Монда сезне һәрвакыт якты йөз, күңелгә хуш килерлек әңгәмә, кызыклы шәхесләр каршы алачак.

**Ландыш ИБРАҺИМОВА,**
**ALTINURTA.RU**
**Фирдүс Минһаҗев фотосы**

# ФӘХРЕТДИН ИШАН

(1804-1891)

***Тау ягының Буа төбәге халкы өчен кылган эш-гамәлләре белән исеме тарихка уелып калган мәшһүр шәхесләрнең берсе Дәмелла Фәхретдин Норлати (Фәхретдин Мостаев) - шагыйрь, мөгаллим, танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул 1804 елны Сембер губернасының Буа өязендәге Норлат авылында (хәзер Татарстанның Буа районына керә) дөньяга килә. Башлангыч дини белемне этисе Мостай хәзрәт мәдрәсәсендә ала. XIX гасырның егерменче елларында укуын Казандагы Иске таш мәчеттә танылган дин галиме Әмирхан бин Габделманнанда (1828 елда вафат) дәвам иттерә. Биредә берничә ел гыйлем өстәгәннән соң, Фәхретдин шәкерт күрше мәхәллә (11нче номерлы мәчет) мәдрәсәсенә күчә. Монда да ул танылган остаз, шул чорның атаклы мәгърифәтчесе булып саналган Әбүбәкер бин Йосыф бин Ильястан (1830 елны вафат) дәрес ала.***



**Гыйлемен** тагын да тирәнәйтү ниятеннән Фәхретдин бин Мостай 22 яшендә ерак Бохарага юл тота. Анда атаклы ишан Шәмсетдин бин Миңле әл-Җәбәлидән (1838 елны вафат) һәм Фәхретдин бине Ибраһим әл-Казани хәзрәтләре хозурында 12 ел белем ала. Шунда аңа ишанлыкка иҗәзәт бирелә. Урта Азиядән әйләнеп кайткач, берара Казанда яши, IV Җәмигъ мәчете мәдрәсәсенә Хәбибулла бин Рәхмәнколый әл-Бики дәресләренә йөри.

XIX гасырның кырыгынчы еллары башында Фәхретдин хәзрәт туган авылы Норлатка әйләнеп кайтып, әтисе мәчетендә имам булып эшли башлый. Егерме ел буена төрле остазлардан алган белемен хәзрәт халкына, яшь буынга ирештерә. Ул уку-укытуга, вәгазьләр сөйләүгә, әхлак тәрбиясе бирүгә бар көчен куя. Фәхретдин дамелла тырышлыгы белән Норлат мәдрәсәсенең даны тиз арада тирә-якка тарала. Елы-елы белән биредә укырга теләүчеләр саны дүрт йөзәр шәкерткә җитә. Зур шәһәрләр өчен дә рекордлы сан була бу. Аның кырык яшьләрдә күз авыруыннан бөтенләй сукыраюы да актив эшчәнлегенә зыян китерми, киресенчә, зур көч, кодрәт өсти.

1880 елны Фәхретдин хәзрәт озын хаҗ сәфәренә юл тота. Хаҗ гамәлләрен үтәгәннән соң, Мәдинә шәһәрендә Казан һәм Бохара якларыннан килгән шәкертләр үтенечен истә тотып, бер ел дәвамында аларга дәрес бирә. Хаҗ вакыты җиткәч, ул янә хаҗ кыла, аннан соң туган якларына әйләнеп кайта.

Аның турында Ризаэддин Фәхреддин болай дип яза: "Мин 1888 елны шәкерт вакытымда Петербург шәһәренә барганымда Фәхретдин хәзрәт үзенең яраннары янында кунакта иде. Шул сәбәпле, бу хөрмәтле зат белән күрештем вә мәҗлесендә булдым. Фазыл вә зәки, яхшы хәтерле, оста сөйләүче, вәгазьләре әсәрле була иде. Мәзәкләр, кызык хикәяләр сөйли иде, әйләнә-тирәсен, бигрәк тә Петербург байларының һәм яраннарының әхвал рухияләрен яхшы беләдер, аларны күңелләндерер, теләсә мәҗлесендә булганнарны елатыр, вә теләсә көлдерер иде...




Бер мәҗлестә аңардан ашауны үтенгәннәр иде. Хәзрәт: "Инде корсакта урын бетте, менә монда гына урын бар", - дип, ике кулын ике кесәсенә куйды. Халыклар әйткәнен аңладылар вә көлештеләр" ("Асар", 4 т., 208 б.).

Фәхретдин хәзрәт XIX гасырның алтмышынчы елларында Тау ягының атаклы, абруйлы шәхесләренең берсенә әверелә. Аның мәдрәсәсе әлеге төбәктә иң эре уку йортлары дәрәҗәсенә генә күтәрелеп калмый, йөзләрчә мөридләр тәрбияләве белән дә үзенчәлекле була. Хәзрәткә шушы төбәкнең, үзе яшәгән, эшләгән мохитнең иҗтимагый-сәяси тормышы да ят булмый. 1870 елны Халык мәгарифе министрлыгының татар укытучылар мәктәбе, рус-татар мәктәпләре ачу, мәктәп-мәдрәсәләрдә рус класслары ачу, мөселман дин әһелләре хәзерләүдә чикләүләр кертү хакындагы законга ул кискен каршы чыга. Законны гамәлгә кертмәсеннәр өчен ул бар көчен куя. Мисал өчен, аның кушуы буенча йөзләгән авыллардан хөкүмәткә бу законга каршы чыга торган прошениеләр языла, протестлар белдерелә...

1889 елны Фәхретдин дәмулла өстеннән Тәтеш өязе исправнигы вазифаларын башкаручы Спиридонов Казан губернаторына шикаять юллый. Әлеге шикаятьтә мондый сүзләр бар: "Слепой мулла деревни Нурлат Буинского уезда... отличается фанатизмом... считается между магометанами святым... имеет большое влияние на татар Тетюшского, Буинского и смежных уездов, все татары в делах религии поступают по его совету..."

Фәхретдин Норлатиның алдан күрүчәнлеге, гипноз көче, шигъри сәләте хакында һәм аның зур ишаннарга хас карамәтләре, хикмәтләре турында истәлек-хатирәләр дә байтак. Әйтик, Фәхретдин дамелланың хаҗга баруы, Санкт-Петербургка Россия императоры Александр II янына могҗизаи сәяхәте, патша хозурындагы галәмәтләре әле дә булса халык телендә.

Фәхретдин ишанның дәвалау, савыктыру сәләте дә көчле була. Шифа алу өчен аңа Россиянең ерак төбәкләреннән килүчеләр бик күп булган. Хәзрәтнең Коръән укуы, тавышы бик матур булган. Ул гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белгән.

Фәхретдин хәзрәт 1891 елны 87 яшендә дөнья куя. Туган авылы Норлатта җирләнә. Аның муллалык, мөдәррислек эшен улы Садертдин Мостаев (1841-1901) дәвам иттерә.

**Рәшид МАЛИКОВ,**
**ТР Фәннәр академиясенең**
**Ш.Мәрҗани исемендәге**
**Тарих институты аспиранты**

# Гашура көне

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Шулай булгач, кардәшләрем, ураза гыйбадәте аша без Раббыбызның рәхмәтенә ирешә алабыз.

Мөхәррәм ае да, Рамазан, Рәҗәп һ.б. айлар кебек үк, изге-шәрәф ай булып санала. Әгәр дә ай буе ураза тоту хәлебездән килмәсә, без Гашура көненең унынчы һәм унберенче көннәрендә генә булса да ураза тотарга тырышырга тиешбез. Ә иң хәерлесе - рәттән өч көн тоту: Мөхәррәм аеның 9 нчы, 10 нчы һәм 11 нче көннәрен ураза белән уздырсак, Аллаһның чиксез рәхмәтләренә ирешербез.

Ләкин без уразаларыбызны нәрсә өчен тотабыз соң? Әлбәттә, гөнаһлардан арыну, пакьләнү өчен. Кайберәүләр: "Ни өчен һаман шул гөнаһлар турында гына сүз алып барасыз", - дип әйтергә мөмкин. Моңа җавап итеп пәйгамбәребезнең (сгв) бер хәдисен китерәсе килә: "Адәм балаларының кылган гөнаһлары, эшләгән хата-кимчелекләре аркасында аларның җилкәсенә бәла-казалар, хәсрәтләр килә. Ләкин кеше үзенең хатасын танып, Аллаһ Раббыбыздан гафу үтенеп, шул гөнаһларыннан тәүбә кылса, шуның белән аның бәла-казалары да китәр", - дип әйткән. Адәм баласы үзенең башына кайгы-хәсрәт килгәч, гаепне үзеннән күрергә теләмичә, башкалардан эзли. Ләкин күпчелек вакытта адәм баласының үзе кылган гөнаһлары аркасында аның башына бәла-казалар килә. Шуңа күрә пәйгамбәребездән (сгв): "Мөхәррәм аеның Гашура көнендә ураза тотсаң, нинди савапларга ирешергә була соң?" - дип сорагач, ул: "Узган елыгызның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен Аллаһы Тәгалә гафу итәр, истигъфар кылыр", - дигән.

Мөхәррәм ае - изге ай. Бу айда кылынган гамәл-гыйбадәтләребезнең, игелекле эшләребезнең әҗер-савабын Аллаһы Тәгалә бик күп мәртәбәләргә арттыра һәм аның хакыйкый әҗерен без Аллаһ Раббыбыз хозурындагы Кыямәт көнендә генә аңлаячакбыз. Ләкин, шул ук вакытта, адәм баласы гөнаһ кылса, аның гөнаһлары өчен дә җәза булачак. Шуны истә тотсак иде. Хакыйкый инану белән инанып, Мөхәррәм айларының һәр көнен гамәл-гыйбадәт кылып уздырырга тырышсак иде. Нәфел уразалары, нәфел намазлары, игелекле эшләр булсынмы, иң мөһиме - шуларны кылырга ашыгып-ашкынып торсак иде. Бер-беребезгә мәрхәмәтле булып, иминлек таратсак иде. Кайберәүләр: "Гыйбадәт - ул фәкать шушы уразадан, намаздан гына гыйбарәт", - дип уйлый. Болай дип уйлаучылар зур хата кыла. Гыйбадәтебез - бер-беребезгә игелек кылу, мәрхәмәтле булу, шәфкатьлелек күрсәтү, ярдәм кулы сузарга тырышу, ярдәмнең нинди генә - матди яисә рухимы - бу да безнең гыйбадәт икәнлеген онытмыйча, Аллаһка ялварып, игелекле эшләр кылырга ашыксак иде. Пәйгамбәребез (сгв) дә бит: "Киләсе елның Мөхәррәм аен күрә алсам, һичшиксез, ураза тотар идем", - дип әйткән булган. Кардәшләрем! Менә безгә Аллаһ Раббыбыз быелгы Мөхәррәм аен күрергә насыйп иткән икән, ураза тотып, гамәл-гыйбадәттә булып, Раббыбызның чиксез рәхмәтенә - шушы дөньяның да, ахирәт тормышының да бәхет-сәгадәтенә ирешергә Аллаһ Раббыбыз һәрбарчаларыбызга да насыйп итсә иде. Әмин!

**Илфар хәзрәт ХӘСӘНОВ,**
**Казандагы Мәрҗани мәчете**
**имам-хатыйбы**
**Эльза Хөснетдинова фотосы**

***Рафикъ хәзрәт ИСЛАМГАЛИЕВ:***

# "БЕЗГӘ БУЙСЫНУ ҖИТМИ"

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Мал-мөлкәт акчалары Сириядә нибары ике ел яшәргә генә җитте. Акча бетә башлагач, товарлар алып, аны сату өчен туган илгә дә җибәрә башладым, сәүдә белән шөгыльләнергә туры килде. Яшисе бар бит. Ул ачлыктан саклап калды, укырга да ярдәм итте. III-IV курсларда укыганда бер фирмага эшкә кердем, алай да атнасына ике генә көн эшли ала идем, чөнки көндезге укуда укый идем бит. Балаларымны да карадым, алар да укуда артта калмады, гарәп телен үзләштерделәр. Кызым Сириянең дипломат балалары укый торган мәктәптә укыды. Барыннан да бигрәк, миңа бу илнең кешеләре ошады.

Анда мөселманнар гади, бер-берсенә ярдәмчел, тәкәббер түгел. Галимнәре дә көчле, аларда да тәкәбберлек юк. Аллаһтан курку, суфыйчылык көчле. Әдәп-әхлак бар. Күңелне, акылны тәрбияләү яхшы куелган. Шәригатьне укыту көчле. Дамаскта иртә-кич дәресләр бара, шәехләр бертуктаусыз дәресләр бирә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) Шам турында күп кенә хәдисләр әйтеп калдырган. Ул: "Шамга һәм Йәмәнгә бәрәкәт бир", - дип Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгаләдән сорый. Шул вакытта сәхабәләр пәйгамбәребездән (сгв) Хиҗазга (хәзерге Әр-Рияд шәһәре урнашкан җирләр. - Р.И.) да бәрәкәт сорый. Пәйгамбәребез (сгв) ишетмәмешкә салышып, югарыда китерелгән сүзләрне янә кабатлый. Сәхабәләр: "Нәҗде өчен дә сора инде, дога кыл", - дип мөрәҗәгать итә. Өченче тапкырында пәйгамбәребез (сгв): "Нәҗде җирләре - ул шайтан мөгезе, шушы җирләрдән фетнә чыгар", - дип җавап бирә. Шам җирләрендә бәрәкәт бар, гыйлем бар. Пәйгамбәребез (сгв): "Шушы Шам җирләрендә Кыямәт көненең зур галәмәтләре башланыр, Мәһди үзенең гаскәрләрен шушы Шамда - Гута исемле җирдә җыяр, Гайсә (гс) Дамаскның көнчыгыш ягындагы мәчет манарасына төшәр", - ди. Ягъни, рәсүлебез (сгв), диндар кешеләрнең шушы Шамда һәм Йәмәндә күп икәнлеген, Кыямәт алдыннан гыйлемле кешеләр фәкать шушы җирләргә җыелыр һәм алар күп булыр, дип искәртә. Алай гына да түгел, мондагы мөселманнарның иманнары көчле һәм күтәренке булыр, ди. Мин исә Дамасктан укып кайткач, билгеле бер сәбәпләр аркасында, 2009-2011 елларда эш таба алмыйча йөрдем. Илдус хәзрәт Фәиз мөфти булып сайлангач, ул кыерсытылган шәхесләрне дә кире какмады. Быел мин мөфтиятнең карары белән Түбән Кама мәдрәсәсе директоры итеп билгеләндем. Шушы мәдрәсәдә реформа (әл-ислах) эшләрен башлап җибәрдем: хәнәфи мәзһәбенә, матуриди гакыйдәсенә таянып, ата-бабаларыбызның гомер-гомергә килгән динебез юнәлешен таратырга, көчәйтергә дигән максат белән эшебезне алып бара башладым. Нинди генә авырлыклар булуга да карамастан, без үзебезнең Әбү Хәнифә юлын һәм матуриди гакыйдәсен киң таратып, юнәлешебезне аныклап, аны республикабыз, илебез киңлекләренә таратырга һәм милләтара татулыкны, бердәмлекне саклап калу юлын бары тик шунда гына күрергә тиешбез, дип уйлыйм. Һәм без дәүләтебезнең киләчәге дә бары тик шушы юнәлешләрдә икәнлеген яхшы аңлыйбыз. Без Президент һәм мөфти куйган бурычларны үтәргә тырышабыз. Түбән Кама шәһәрендә шул юнәлештә эш алып барыла.

***- Ә Татарстаннан Сирия башкаласы Дамаскка сездән кала тагын укырга китүчеләр булдымы?***

- Әйе, булды. Мәсәлән, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсеннән Илнур исемле егет ныклап Коръән ятлап кайтты. Кызганыч, бүгенге көндә дини гыйлем артыннан йөрүчеләрнең күбесе үзләрен дин өлкәсендә таба алмый. Сәүдә, сату-алу эше белән көн күрә башлыйлар. Дингә хезмәт итмиләр. Бу бик тә кызганыч. Әлбәттә, бизнеста күп акча эшләп була, гаиләне тотуы да җиңел, яхшы "иномарка"ларда да чабып була. Әмма боларның барысы да вакытлыча. Дөнья - ул бары тик мизгел генә. Татарстаннан укырга чыгып китеп, аннан соң республикабызга кайтып, дингә хезмәт итмәүчеләр артканнан арта бара. Мәдрәсәләрдә кадрлар мәсьәләсе баш авыртуы булып кала бирә.

***- Кайсы гарәп илләре сез күрсәткән юнәлешләр буенча хезмәт куеп, зур уңышларга ирешә?***

- Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә: "Сез яратмаган әйбердә хәер бар. Яраткан әйберегездә исә начарлык, бозыклык бар", - дип әйтә ("Бакара (Сыер)" сүрәсе, 216 нчы аять). Сириядә хәнәфи һәм шәфигый мәзһәбләре урнашкан. Шулай ук Гыйракны алыйк.

Ул Америка белән бәйләнешкә кергәнче, анда зур үсеш бара иде. Ә Согуд Гарәбстаны, Кувәйт кебек илләрдә байлык та җитәрлек кебек, ләкин анда яшәүче кешеләренең рухи халәтләре башкачарак. Шул ук Мисыр, Шам илләре (Сирия, Иордания, Фәләстыйн, Ливан) кешеләрен карасак, аларда үзенчәлек бар. Аларда ислам диненең асыл тамырлары калганга күрә, кешелеклелек зур, гадилек, ихласлык көчле. Ә Согуд Гарәбстаны кешеләре әллә каян аерылып тора. Аларның үз-үзләрен тотышы, башкаларга булган карашы, бүтәннәргә мөгамәләте безнең өчен гаҗәп тоела. Менә шушы мәзһәб-юнәлеш хәтта кешенең әдәбенә, аның үз-үзен тотышына, яшәешенә, әдәп-холкына да тәэсир итә. Череп баеганнарда кешелеклелек сыйфатлары, күп очракта, бик үк югары дәрәҗәдә түгел. Ә шамлыларда суфыйчылык көчле. Нәрсә соң ул суфыйчылык? Ул - кешенең үз әдәп-әхлагын, йөрәген сафландыру һәм тәрбияләү өстендә эшләве. Ләкин ул дөньяны ташлау, байлыктан ваз кичү дигән сүз түгел. Суфый нәрсә эшли? Ул эчке дөньясын тәрбияли, ихласлылыгын үстерә, калебен чистарта. Һәм бу эшләр синең тышкы кыяфәтеңдә үз җимешләрен бирә. Мисалга Йәмәнне алыйк. Ни өчен пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) Шам белән Йәмәнгә дога кылды? Чынлыкта (моны бүгенге көн галимнәре дә әйтә), шушы як кешеләре үзләренә күрә аерылып тора. Бу як халкы үзгә. Мөселманнарга хас сыйфатлар аларда ярылып ята. Кимчелекләре дә бар, әмма аларның әдәбе, үз-үзләрен тотышы, бүтән гарәп мөселманнары белән чагыштырганда, әллә каян аерылып тора.

***- Ә бүгенге мөселман өммәтенә нинди сыйфатлар җитми дип саныйсыз?***

- Бүгенгесе көндә Коръәндәге аятькә таяну җитми: "Ий мөэминнәр! Аллаһка итагать итегез һәм рәсүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездән булган Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче дини хуҗаларыгызга да итагать итегез! Әгәр бер дини мәсьәләдә бәхәсләшсәгез, ул мәсьәләне Аллаһ китабы Коръәнгә кайтарыгыз! Әгәр Коръәндә ачык хөкем табылмаса, ул вакытта рәсүлнең (гс) гамәленә кайтарыгыз! Әнә шулай һәр эшне Коръән, сөннәт үлчәве белән хәл итсәгез, сезнең өчен хәерле һәм ахыр нәтиҗәсе күркәмдер. (Бу аятьтә ачык мәгълүм булды ки: көчле иман, дөрес дин Коръән, сөннәт белән гамәл кылганда гына буладыр. Коръән, Сөннәт белән гамәл кылмау Аллаһка һәм ахирәт көненә иманның юклыгына дәлил була аладыр)". ("Ниса (Хатыннар)" сүрәсе, 59 нчы аять). Мөфти куелган икән, без - бөтен мөселманнар, нинди генә мәзһәб, юнәлеш, караштә булмыйк, шушы әмиребезгә буйсынырга тиешбез. Хәзерге вакытта шул буйсыну җитми. Бөтен фетнә,



ыгы-зыгылар килеп чыгуның төп сәбәбе - буйсына белмәүдә. Мөселманнарда төрле караш, төрле уй-фикер хөкем сөрә. Бүгенге көндә безнең бәхәсләшү әдәбебез дә коточкыч. Хәзерге мөселманнар интернетта бәхәсләшә. Ә карагыз - әдәп бармы анда? Коръәнгә, сөннәткә буйсыну булмагач, төп чиребез дә шунда: һәрбер дини юнәлеш үзен өстен куярга тырыша. Минеке генә дөрес, ди. Әмиргә буйсыну җитми. Син нинди генә караштә булсаң да, әмир куелган икән, буйсынырга тиешсең. Бабаларыбыз меңәр ел буе түкми-чәчми алып килгән ислам динен! Татарстан җиренә теләсә-нинди мәзһәб-юнәлеш кертмәгән бит алар! Аны алып керү өчен ул вакытта да мөмкинлекләр җитәрлек булган. Элек тә Мисырда, Шамда, Төркиядә укучылар булган бит. Урта Азиядә, Үзбәкстанда, Гарәбстанда укыган галимнәребез дә бар. Аларга да төрле юнәлешләр алып кайтырга мөмкинчелек булмаганмы? Әлбәттә, булган. Тик, нихәл итсәләр иткән, кертмәгәннәр бит. Ул вакытта да уй-фикерләр төрле булган, ләкин ыгы-зыгы, фетнәләр китереп чыгармаганнар. Тату, әдәпле итеп динне алып барганнар. Бер фикердә, бер юнәлештә булганнар. Дөрес, карашлар үзгәреп тора. Әмма мөфти бер бит. Бердәмлек булганга күрә, элек халкыбызның данлыклы галимнәре дә бихисап булган. Мисал өчен, Әхмәдһади Максуди, Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиевләр... Әгәр дә без буйсынмыйбыз, бердәм булмыйбыз икән, безнең эшебезнең дә нәтиҗәсе булмаячак. Татарстанда инде менә егерме елдан артык дин иреге. Ләкин бу чор эчендә кулга тотарлык галимнәребез үстеме соң? Галимнәрне утыз-кырык яшьтән түгел, биш-алты яшьтән тәрбияләргә кирәк. Безнең егерме ел эчендә галимнәр үстерергә мөмкинлек бар иде, әмма без моны эшли алмадык. Революциягә, хәтта 1936 нчы елларга хәтле безнең Казан, Татарстан нихәтле галимнәр биргән! Мисал өчен, дөньяви фәннәр - математика, физика, химияне генә алыйк. Лобачевский, Бутлеровлар... Казан бөтен дөньяга органик химияне бүләк итте. Мәрҗаниләрне бүген бөтен гарәп дөньясы белә. Ә без - шушы Татарстаныбызда яшәп, аларның хезмәтләрен шәкертләребезгә өйрәтергә кыенсынып торабыз. XIX-XX гасырларда безнең галимнәребез (Мәрҗани, Бигиев, Максудиләр һ.б.) Европа галимнәре белән хат язышты, фикерләр алышты. Европалылар да мөселман дөньясы белән ныклы элемтәдә торды (ул вакытта аларның мөселманнарга хөрмәте зур иде). Татар галимнәре үзләрен зур фикер ияләре итеп танытты, алар дөнья күләмендә даншөһрәт казанды һәм безнең көннәрдә дә аларның фикерләрен сәясәтчеләр, икътисадчылар, дин әһелләре үз хезмәтләрендә чагылдыра. Безгә бу дәрәҗәләргә ирешү өчен яшьләребездә дингә мәхәббәт уятырга кирәк, ник дисәң дә, бүгенге татар яшьләре арасында, Кавказ, Урта Азия төбәкләре белән чагыштырганда, дин гыйлемен үзләштерүчеләр аз санда бит. Фикеремне саннар белән ныгытам. Мин укыган елларда Россиядән Дамаскка бары илле кеше, Кавказдан - биш йөз, ә Урта Азиядән меңләгән кеше килеп укыды. Әгәр дә моны халкыбыз аңлап җиткермәсә, татарлар арасында ислам динен әйдәп баручылар булмаячак. Бу - бик тә кызганыч, аяныч хәл булыр. Моңа бармак аша гына карарга ярамый. Бу акылга, дөрес фикер йөртүгә һәм Татарстаныбызның киләчәк үсеше, аның чәчәк атуы белән нык бәйләнгән.

**Әңгәмәдәш - Нияз САБИРҖАНОВ**

## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 3.12.12 | 7:21 | 08:51 | 13:02 | 15:11 | 16:14 | 17:44 |
| Якшәмбе | 4.12.12 | 7:22 | 08:52 | 13:02 | 15:10 | 16:13 | 17:43 |
| Дүшәмбе | 5.12.12 | 7:24 | 08:54 | 13:02 | 15:09 | 16:13 | 17:43 |
| Сишәмбе | 6.12.12 | 7:25 | 08:55 | 13:02 | 15:09 | 16:12 | 17:42 |
| Чәршәмбе | 7.12.12 | 7:27 | 08:57 | 13:02 | 15:09 | 16:12 | 17:42 |
| Пәнҗешәмбе | 8.12.12 | 7:28 | 08:58 | 13:02 | 15:09 | 16:11 | 17:41 |
| Җомга | 9.12.12 | 7:29 | 08:59 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| Шимбә | 10.12.12 | 7:31 | 09:01 | 13:02 | 15:08 | 16:10 | 17:40 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №16 (113) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-516.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 1 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**